**ЯШЬНӘП ҮТКӘН ГОМЕР**
**Рахмай Хисмәтуллинга**
**80 ел тулу уңае белән әдәби-музыкаль кичә**
*(югары сыйныф укучылары өчен)*

*Талгын гына көй астында сәхнә артыннан егет тарафыннан шигырь укыла.*

**Егет:**

Серле әкият, матур әкият
Кебек дөнья.
Башы да юк, юктыр аның
Азагы да.
Татлы аның михнәте дә,
Газабы да.
Ерак, ерак күп йолдызлар
Бизи күген.
Җир ашкына чиксезлеккә,
Белми чиген.
Чиксезлекне беркем җирдә
Хис итмәгән,
Әкиятне дә һичкем тулы
Ишетмәгән.
Һәркем өчен, кем килсә дә
Бу дөньяга,
Матур әкият һаман серле,
Һаман яна.

*«Һаман яна»*

*Көй дәвам итә, сәхнәгә ике алып баручы чыга*

**1нче алып баручы:** Матур әкият һаман серле, һаман яна.

Хәерле көн. Бүгенге кичәбез күренекле язучы, Гаяз Исхакый исемендәге әдәби бүләк иясе Рахмай Хисмәтуллин иҗатына багышлана.

**2нче алып баручы:** Рәхмәтулла Хисмәтулла улы Хисмәтуллин – матур табигате җырларга күчкән Актаныш районы егете. Әнәк авылында 1934 елның 25нче сентябрендә туа. 1952 елда – Пучы урта мәктәбен, аннан Казан дәүләт университетының физика-математика факультетын тәмамлый. Күңелендә сандугач оялагач, нишлисең. Рахмай Хисмәтуллин дипломлы физик-математик булуына карамастан, башта Питрәч аннан Азнакай район газеталарында, соңрак Казанда «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») журналында эшли.

**1нче алып баручы:** Журналист һәм язучы һаман эзләнә, аны яңа юллар дәшә. Тынгысыз язучыны төзелеш мәйданнары, төрле һөнәр ияләренең, төрле

оешмаларның тормышлары кызыксындыра. Шуңа күрә ул Казан оргсинтез заводы төзелешендә бетончы, үзе укыган университетның хисаплау үзәгендә математик-программист булып хезмәт куя.

**2нче алып баручы:** 1966-1978 елларда Түбән Кама шәһәрендә яши. Төзелештә инженер, укытучы, халык театры режиссеры вазифаларын башкара. Соңгы һөнәре, әдипкә илһам биреп, халык арасында абруен күтәрә, «Җидегән чишмә» бәйрәмнәренең тууына китерә. «Җидегән чишмә» берләшмәсе язучылар, артистлар, композиторлар, галимнәр өчен, гомумән, халкыбызның күренекле иҗат әһелләре өчен бик мактаулы кунак урыны була.

**1нче алып баручы:**Рахмай Хисмәтуллин тугыз китап авторы. Авторның китап исемнәре дә үз характерына туры килеп торалар: «Салават күпере», «Күкрәү авазлары», «Үземне таптым», «Сусау», «Дөньяга көлеп чык!», «Яшенле тау», «Ак догалар», «Кыйбла җиле», «Тәүбә».

1991 елда язучыга «Кыйбла җиле» исемле китабы өчен Татарстан Язучылар берлегенең Гаяз Исхакый исемендәге әдәби премиясе бирелде.

**2нче алып баручы:** Рахмай Хисмәтуллинның бер шигырендә мондый фәлсәфи юллар бар:

Бик аңлыйсым килә
бер серне – үлемне;
Һич тоттырмый торган
бер көчне – үземне...

Кеше үзен аңларга тырыша, үзен эзли, үзен ача. Ничек ача? Менә инде анысы һәркемнең үзеннән тора. Язучының үзе исән вакытта ук басылып чыккан, үз-үзе белән көрәшүдән туган «Яшьнә, язучы!» дип исемләнгән мәкаләсендә бу сорауга күпмедер дәрәҗәдә җавап табарга мөмкин.

*Талгын гына көй агыла.*

**1нче укучы:** «*...Язучы һәм язучылык беркайчан да үлмәде һәм үлмәячәк. Чөнки ул әле күрәзәче, әле камчы, әле багучы, әле табибчы, әле җыручы булып, билгесез чорлардан яралып чыгып, һуннар һәм сөннәр дәверләрен бөек татар телендә мәңгеләштергән. Син, Язучы, ил-көн өстендә өметсезлек куерганда гасырларны ялгаучы Равил Фәйзуллин булып:*

*Кануннар шартлап ярылды.*
*Ил-җирләр тетрәнде.*
*Әтрәк-әләмнәр көрәйде.*
*Хезмәтле – бөкерәйде. –*
*дип хакыйкатьне ярып салдың.*

*Син, Язучы, бүген батырҗан шагыйрь Разил Вәлиев булып, үч, нәфрәт дошманлык ярларыннан ташып чыккан кыядай күтәрелдең. Туган телне һәм Вөҗданны, ваклык һәм сатлыклардан аралап, иң алгы биеклеккә чыгарып бастырдың.*

*Яшьнә, Язучы, иң тәкәбберләрең дә, иң әллә кемнәрең дә бу бөтенкешелек аек яшәү кайгысы каршында бик бәләкәй булып калып, иман китерсен!*

*Яшьнә, Язучы, яшәсен ачлыктан вә вакыттан, дәүләттән вә хакимнәрдән өстен мәңгелек рух иле!*

*Яшәсен Рухстан!».*

*«Яшьнә, язучы!» әсәреннән өзек.*

**1нче алып баручы:** Яшьнә, Язучы, яшә мәңгелек рух иле! Яшәсен Рухстан! Язучы Рахмай Хисмәтуллин яшьнәп яшәде, аның безнең арадан киткәненә дә бер дистә еллар вакыт үтеп киткән. Язучы иҗаты яши, нәкъ менә үзе язып калдырганча ул мәңгелек.

Рахмай Хисмәтуллинның хикәя, нәсер, шигырьләре вакытлы матбугатта басыла.

*Укучылар чыгышы.*

**2нче укучы:**

Моңсу уйлар баса кайчакларда:
Карап утырам янган учакларга.
Их, бер җыеп бабамнарның барысын,
Рәхәтләнеп, сагынып кочакларга!

Уй йөгерә ерак-еракларга:
(Уйсыз яшәү – хурлык ир-атларга)
Бабамнарның туфраклары гына
Меңесенең ята мең якларда.

Җитте вакыт азат-хөр эшләргә!
Тарихларны ныклап дөресләргә!
Юлсыз калган милләт баласына
Чынын ачу кирәк дәресләрдә.

Җаннар китә, китә еракларга...
Туфрак тәннәр кала зиратларда.
Әмма тоям: бабаларның рухы
Яшәп ята батыр ир-атларда.

«*Уйласаң уй, китә еракларга...* »

**3нче укучы:**

Әкрен генә, талгын гына

Тибрәнеп яшь кар ява.
Безне кочып күтеп ала
Тап-таза төнге һава.

Иркә карлар уйный нурда
Назланып, канатланып...
Керфекләреңдә эриләр,
Күзләреңә таң калып.

Ак урамнар, ак бар дөнья,
Төнбоектай калфагың.
Күңелебезнең ак дөньядай
Керсез чагы, аппагым.

Яшьлекнең бу – туй аклыгы,
Ак моңнар гел як-ягым.
Бу – син бу, кереп күңелгә,
Бар дөньяны пакъладың.

«*Аклык җыры*»

**2нче алып баручы:**Кадерле язучылар, хөрмәтле кунаклар, әйтерсең лә бүген язучы безнең белән, ул читтән генә безне күзәтә, сөенә, горурлана. Һәм безне шигърият мәйданында бергә бер бөтен итеп туплап тота, яшәтә.

*Җыр башкарыла.*

**Җыр:**

Ак кына син, пакъ кенә син,
Ак кына беләкләрең.
Саф кына күңелләремнән
Сөяргә теләкләрем.

Ак кына син, пакъ кенә син,
Ак кына күлмәкләрең.
Кемне күргәч, ашкына да
Җилпенә йөрәкләрең.

Яшь кенә пакъ кулларыңа
Кем дә ул тидермәгән.
Кемнәрне син бер караудa
Яндырып көйдермәгән.

Пакъ кенә шул...Чак кына да
Күтәреп күз бакмыйсың.
Пакъкенә булган өчен дә

Чын бәхеткә хаклы син.

*«Ак кына син»*

*(Рахмай Хисмәтуллин сүз, Риф Гатауллин көе)*

**1нче алып баручы:** Рахмай Хисмәтуллин 1989 елда Чаллы каласына килә. 1997 елга кадәр Чаллы Язучылар оешмасын җитәкли.

Чаллыга күченеп килгәч, Рахмай Хисмәтуллин бер-бер артлы шигырь китаплары иҗат итте. Соңгы елларда ул туган авылы тарихына багышланган «Яшьнәү белән күкрәү арасы» исемле кыйсса-трилогия яза башлаган иде. Өч томнан торырга тиешле бу кыйссага нокта куелмый калды. Язучы трилогиянең «Әнәк имәннәре» исемле беренче өлешен генә язып тәмамларга өлгерде.

*Талгын гына көй агыла.*

**4нче укучы:**

«*...Төзелеп бетмәгән мәчеттән дә сихерле, тылсымлы урын юктыр ул. Өмет һәм илаһи хыял тулы анда... Каяндыр мәчет түбәсеннән моңлы бер аваз яңгырагандай булды.*

- *Яңадан мәңге булмас тамашаны карап кал!*

*Дөп-дөп-дөп! Туп-туп-туп! Гүя ат тоягы тавышлары йөрәк тибешләренә кушылып яшен булып яшьни, күк булып күкри иде. Кинәт, канатларын бик каты кагып, пырылдатып, мәчет эченнән ап-ак күгәрчннәр очып чыктылар. Ил Агасының баш очында әйләнә үк башладылар. Чебен очкан тавышлар да ишетелерлек булып бар дөнья каып-тынып калды. Бөтен кеше гүя тораташ иде.*

*Җидәү иде ул ап-ак күгәрчен...*

*Дөп-дөп, туп-туп...Уфет-өфет, фет-фет, ферш-ферш. Алар, бар гавамны вә галәмне таң калдырып, җиде фәрештәгә, ак күлмәкле, чигүле ак алъяпкычлы, ак яулыклы җиде Олуг Анага әверелеп, Илбашын әйләндереп алдылар*».

*«Әнәк имәннәре» әсәреннән өзек.*

**1нче алып баручы:**

Минем турыда кайчак мактау булса,
Зинһар, кызыкмагыз, көнләшмәгез.
Үзем генә беләм бәхетемнең
Миңа ничек итеп эндәшкәнен.

Кайчак кызып авыр сүзләр әйтсәм,
И дусларым, зинһар кичерегез.
Төннәр йоклый алмый үкенеп ята
Сер-тел тотмас юньсез бу тилегез.

И дусларым, сезнең яхшылыкны
Уйлап ятам һаман тик сез юкта...

Тетрәп китәм: сезгә әйтелмәгән
Рәхмәтләрем җанда тулгак тота.
*«Төнге тәүбә»*

**2нче алып баручы:** Рахмай Хисмәтуллинга шигырь, очерклар, мәкаләләр язып ятса да җиткән бит инде. Ә ул авылларда йөреп борынгы китаплар, кулъязмалар эзли. Тарих белән кызыксына. Унбиш ел «Кама таңнары» әдәби берләшмәсенә җитәкчелек итә. Берләшмәдә өметле яшьләр шактый. Ул яшь талантларга булыша, ярдәм итә.

И бар да соң ярлылар!
Байлык-муллыкларда йөзеп,
Алтын-зиннәтләргә күмелеп,
Бәхет даулыйлар.

Рахмай Хисмәтуллин да үз бәхетен эзли. Тормышта яшьнәп, янып эзли.

**1нче алып баручы:** Рахмай Хисмәтуллин халык өчен һәм халык мәнфәгатен кайгыртып яшәде, эшләде. Рахмай абый сигез генә юллык шигырендә үзе турында болай ди:

Ниләр булса да ил белән:
Тәмугым да, оҗмахым да.
Гафу ит, кайчак сөйләнсәк –
Хагын да, нахагын да.

Нинди вакытың булмасын,
Син, илем – газиз Ватан.
Син миңа гомер – җан биргән,
Син анам һәм дә атам.

**2нче алып баручы:** Рахмай Хисмәтуллин эшләгән Түбән Кама, Яр Чаллы калалары ил күләмендә, бик кыска вакыт эчендә танылып өлгерде. Алар бер-берсе белән ярышып күтәрелделәр. Безнең төбәкнең сәнгать көчләре дә үзләренә тиң урыннарны яулый, шулар арасында Рахмай Хисмәтуллин да бар.

**1нче алып баручы:** Кичәбезне Рахмай Хисмәтуллинның шигъри юллары белән тәмамлыйсы килә.

**2нче алып баручы:**

Их, кардан арынып җир чыгулар!..
Җиргә карап татлы җирсенүләр...
Ак каен кебек пакъ буласы иде.
Шаян җил кебек саф буласы иде.

**1нче алып баручы:**

Ак болытлар булып йөзәсе иде.
Күктә тургай сыман җыр сузасы иде.
Көмеш күлләрдә камыш буласы иде,
Япь-яшь көләч тавыш буласы иде.

**2нче алып баручы:**

Дәрт тулы туфрак буласы иде.
Яралу, шыту белән туласы иде.
...Бар белгәнне онытып, ташлыйсы иде.
Гомерне өр-яңадан башлыйсы иде!

*«Яңадан яралу теләү»*

**1нче алып баручы:** Гомерне яңадан яшәп булмый. Ләкин язучы бәхетле, аның иҗаты үзеннән соң да яши.

**2нче алып баручы:** Кадерле укучылар, бүгенге кичәбез яшьнәп үткән гомер хуҗасы язучы, публицист, Гаяз Исхакый исемендәге әдәби бүләк иясе Рахмай Хисмәтуллин иҗатына багышланды.

## Файдаланылган әдәбият

Хисмәтуллин, Р. Төнге тәүбә, Билгесез шатлык; Яңадан яралу теләү; Барыбер яфрак ярачак!: шигырьләр / Р. Хисмәтуллин // Аргамак. – 1994. – № 10. – Б.62-63.

Хисмәтуллин, Р. Яшьнә, язучы!: публицистик мәкалә / Р. Хисмәтуллин // Мәдәни җомга. – 1995. – 21 июль.

Хисмәтуллин, Р. Һаман яңа: шигырь / Р. Хисмәтуллин // Кешеләр һәм чәчәкләр / төзүчеләр Г. Ахунов, Ә. Маликов. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1968. – Б.85.